ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

01. 07. 2019　　　　　　г.Мензелинск　　　　　　№ 663

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының башкарма комитеты җитәкчесенең 11.04.2014 елдагы "Төзелеш, архитектура һәм ТКХ өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларны раслау турында"гы №336 карарына үзгәрешләр кертү турында

19.07.2010 елдагы "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" гы №204-ФЗ Федераль законына кертелгән үзгәрешләргә, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшкәртү һәм раслау Тәртибенә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, 24.07.2018 елдагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының №593 карары белән, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламентларын РФ законнары белән тәңгәллеккә китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1.Яңа редакциядә расларга:

- 1.1.Социаль түләүләр кулланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнарны исемлеккә кертү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә һәм авыл җирлегендә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләүләр бирү турында таныклык бирүгә административ регламент.
- 1.2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны учетка кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

2. Гамәлдәге карарны п.1.1.1. белән тулыландырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1.1."2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" подпрограммасы буенча торак сатып алуга (төзелешенә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык алу һәм учетка кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеген начальнигы Е.А.Басковка йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев